| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.11.2019 Олы Кайбыч ав. № 512

«2020 елга Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районында
юл хәрәкәте иминлеген арттыру»
муниципаль максатчан Программасын раслау турында»

Автомобиль транспортында һәлакәтләрне һәм юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәләрен киметү, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм аларның мөлкәтен саклауны тәэмин итү, аларның законлы хокукларының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы юлларында хәвефсез хәрәкәт шартларына гарантияләрен арттыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 6 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен киметъ һәм алардан килгән зыяннарны азайту чараларын гамәлгә ашыру турында» 2018 елның 17 декабрендәге 1149 номерлы карарын үтәү өчен, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән «2020 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан Программасын расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты
Җитәкчесенең 2019елның 29 ноябрендәге 512
номерлы карары белән расланды

# «2020 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан Программасы

Олы Кайбыч ав.

# «2020 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан Программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2020 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан Программасы |
| Программа эшләү өчен нигез | "2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру" федераль максатчан программасы турында" РФ Хөкүмәтенең 2013 елның 3 октябрендәге 864 номерлы карары (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)<br><br>«Татарстан Республикасы буенча юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 06 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы<br><br>«2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (2019 елның 9 октябренә үзгәрешләр белән)<br><br>«Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен кыскарту һәм аларның нәтиҗәләрен киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2018 елның 17 декабрендәге 1149 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |
| Программаның заказчысы | ТР Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүчеләр | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге, Россия ЭЭМның Кайбыч районы бүлекчәсенең ЮХИДИ бүлекчәсе |
| Программаның үтәүчеләре | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге, Россия ЭЭМның Кайбыч районы бүлекчәсенең ЮХИДИ бүлекчәсе, «Кайбыч РҮБ» ДАССУ, РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 18 номерлы янгын сүндерү бүлеге, ТР Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләренең башкарма комитетлары, подрядчы һәм проектчы оешмалар. |
| Программаның | Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар санын |

| | |
|---|---|
| максатлары һәм бурычлары | киметү;<br>юл-транспорт һәлакәтләре белән зыян күрүчеләр санын азайту.<br>Программаның бурычлары түбәндәгеләр:<br>-юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тотышын кисәтү;<br>юл-транспорт травматизмын, шул исәптән балалар травматизмын кыскарту;<br> - транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерү;<br>-балаларда һәм яшүсмерләрдә транспорт культурасын тәрбияләү;<br>-автомобиль юлларының муниципаль челтәрен үстерү. |
| Программаны тормышка ашыруның сроклары һәм этаплары | 2020 ел |
| Программаны финанслау чыганаклары | Республика бюджеты 35,0 млн. сум, бюджеттан тыш чыганаклар 0,04 млн. сум, муниципаль бюджет 23.0 млн. сум. |
| Программа үтәлешен тикшерүне оештыру | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты.<br>Кайбыч муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | База 2012 ел белән чагыштырганда Программа индикаторларының уңай күрсәткечләренә ирешү:<br>транспорт куркынычлыгын, социаль куркынычны, нәтиҗәләрнең авырлыгын киметү;<br>юл-транспорт һәлакәтендә үлүчеләр санын киметү;<br>юл-транспорт һәлакәтләре концентрациясе урыннарын киметү;<br>юл-транспорт һәлакәтләре санын, шул исәптән балалар катнашындагы һәлакәтләрне киметү. |

## Кереш

Юлларда транспорт һәлакәтләре (юл-транспорт һәлакәтләре) иң җитди социаль-икътисадый проблемаларның берсе булып тора. Юл хәрәкәтендә катнашучыларның гомерен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итү районның социаль-икътисадый үсешенең өстенлекле юнәлешләре рәтенә керә.

Җирле әһәмияттәге автомобиль юллары муниципаль район инфраструктурасының мөһим элементы булып тора, 2020 елның 1 гыйнварына аларның озынлыгы:

| Исеме | Озынлыгы, км | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Асфальт | Вак таш | Грунт |
| Олы Кайбыч ав. юл-урам челтәре | 25,59 | 21,02 | 2,97 | 1,59 |
| Җирлекләрнең юл-урам челтәре | 215,55 | 21,87 | 49,92 | 143,77 |
| Муниципаль автомобиль юлларын исәпкә алмыйча | 30,69 | 0,68 | 1,55 | 28,46 |
| авыл җирлекләренең һәм шәһәрнең урам-юл челтәре | 271,83 | 43,57 | 54,44 | 173,82 |
| Җирле әһәмияттәге юлларның гомуми озынлыгы | 229,26 | 175,22 | 17,14 | 36,9 |
| Региональ әһәмияттәге юлларның озынлыгы | 501,09 | 218,79 | 69,41 | 212,89 |
| Районда барлык автомобиль юллары | 58 | | | |
| Районда торак пунктлар саны | 10 (24,86 км.грунт) | | | |

### Теркәлгән транспорт чаралары саны

| еллар | теркәлгән | Физик затлар | Юридик затлар |
|---|---|---|---|
| 2012е. | 4045 | 3608 | 437 |
| 2013е. | 4287 | 3824 | 463 |
| 2014е. | 4499 | 4014 | 485 |
| 2015е. | 4715 | 4206 | 509 |
| 2016е. | 4917 | 4382 | 535 |
| 2017е. | 4829 | 4320 | 509 |
| 2018е. | 4944 | 4491 | 453 |
| 2019елның 9ае | 5028 | 4561 | 467 |

**Аварияләр торышы**

| Еллар | барлыгы ЮТҺ | Материаль Югалту белән | Зыян күрүчеләр белән А-Б-В |
|---|---|---|---|
| 2012 | 152 | 135 | 17-9-19 |
| 2013 | 155 | 141 | 14-2-24 |
| 2014 | 144 | 127 | 17-4-21 |
| 2015 | 99 | 89 | 10-4-12 |
| 2016 | 97 | 89 | 8-4-13 |
| 2017 | 113 | 102 | 11-4-15 |
| 2018 | 64 | 59 | 5-0-6 |
| 2019елның 9ае | 6 | 6 | 6-0-12 |

А (саны) – Б (үлүчеләр) – В (җәрәхәтләнүчеләр)

**Балалар катнашындагы аварияләрнең торышы**

| Еллар | Балалар катнашында барлыгы ЮТҺ | Зыян күрүче балалар белән А-Б-В |
|---|---|---|
| 2012 | 2 | 2-1-1 |
| 2013 | 1 | 1-0-1 |
| 2014 | 2 | 2-0-2 |
| 2015 | 2 | 2-0-2 |
| 2016 | 0 | 0-0-0 |
| 2017 | 2 | 2-0-2 |
| 2018 | 1 | 1-0-2 |
| 2019елның 9ае | 0 | 0-0-0 |

А (саны) – Б (үлүчеләр) – В (яраланучылар)

**ЮХК бозу төрләре буенча**

| еллар | ЮХК бозу төрләре | | |
|---|---|---|---|
| | Машина йөртүчеләр гаебе белән | Аек булмаган машина йөртүчеләр гаебе белән | Җәяүлеләр гаебе белән |
| 2012 | 12-8-18 | 1-0-2 | 2-1-1 |
| 2013 | 14-2-24 | 3-0-8 | 0-0-0 |
| 2014 | 17-4-20 | 2-0-3 | 1-0-1 |
| 2015 | 10-4-12 | 3-0-3 | 1-1-0 |
| 2016 | 7-4-7 | 4-4-6 | 0-0-0 |
| 2017 | 11-4-15 | 3-3-2 | 1-0-1 |
| 2018 | 5-0-6 | 1-0-1 | 0-0-0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2019елның 9ае | 3-8-12 | 1-0-1 | 0-0-0 |

**ЮТҺ сәбәпләре буенча**

| № | ЮТҺ сәбәпләре | ЮТҺ саны | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| 1 | Тизлек режимын бозу | 17 | 21 | 6 | 1 | 0 | 2 | 2 | 3 |
| 2 | Аек булмаган хәлдә идарә итү | 2 | 2 | 2 | 3 | 4 | 3 | 1 | 1 |
| 3 | Узып китү кагыйдәләрен бозу | 0 | 2 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 2 |
| 4 | Йөртү хокукыннан башка идарә итү | 1 | 3 | 1 | 0 | 0 | 1 | 0 | 0 |
| 5 | Дистанция сакламау | 30 | 13 | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 6 | Техник халәт | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 7 | Юл чатын узу | 14 | 12 | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 8 | Каршы як хәрәкәте полосасына чыгу | 1 | 3 | 5 | 5 | 3 | 2 | 1 | 0 |
| 9 | ЮХКК башка бозу очраклары | 17 | 27 | 2 | 0 | 1 | 3 | 1 | 0 |

**ЮТҺ килеп чыгу урыннары бүленеше**

| ЮТҺ булган урын | Кол-во ДТП | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019елның 9ае |
| Юл - урам челтәре | 96 | 98 | 74 | 4 | 0 | 3 | 0 | 0 |
| Муниципаль әһәмияттәге гомуми | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 2 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| файдаланудагы юллар | | | | | | | | |
| Гомуми файдаланудагы региональ әһәмиятле юллар | 39 | 43 | 53 | 6 | 8 | 8 | 5 | 4 |

## I. Проблеманың характеристикасы

Юл-транспорт һәлакәте икътисадка зыян китерә, ул түбәндәгеләрдән тора:

- амбулатор һәм стационар дәвалануга, зыян күрүчеләрне транспортировкалауга чыгымнар;
- реабилитациягә чыгымнар;
- үлем яисә кешеләрнең хезмәткә даими сәләтсезлеге сәбәпле алынмаган продукция чыгымнары;
- мөлкәтне зарарлауга, юл буе коммуникацияләрен торгызуга бәйле чыгымнар;
- юл-транспорт һәлакәте сәбәпләрен тикшерүгә чыгымнар, иминият суммаларын түләүне оештыру, суд чыгымнары;
- юл-транспорт һәлакәтенә бәйле рәвештә вакыт югалтуга бәйле чыгымнар.

Һәлак булучыларның һәм юл-транспорт һәлакәтендә имгәнү алучыларның туганнарына, якыннарына, хезмәттәшләренә китергән әхлакый зыян бәяләп бетергесез.

Муниципаль район юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү һәм алардан килгән зыянның авырлыгын киметү бүгенге көндә башкарма хакимиятнең мөһим бурычларыннан берсе булып тора.

2019 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча, "2013 - 2020 елларда юл хәрәкәте куркынычсызлыгын арттыру" Федераль максатчан программасы күрсәткечләре буенча (АПГ 2012 (17-9-19), район территориясендә шартлы рәвештә үтәлгән.

2019 елның 9 ае дәвамында зыян күрүчеләр белән 6 юл-транспорт һәлакәте булган, алар вакытында 12 кеше яраланган.

Кайбыч муниципаль районында авария булу-булмавын билгеләүче төп факторларга түбәндәгеләрне кертергә кирәк:

- юл хәрәкәтендә катнашучылар тарафыннан юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләрен үтәмәү, транспорт чаралары белән идарә иткәндә машина йөртүчеләрнең игътибарсызлыгы һәм игътибарсызлыгы;
- юл хуҗалыкларының, юл хәрәкәтен оештыру чараларының бүгенге заман таләпләренә туры килмәве. Районда зыян күрүчеләр булган юл-транспорт һәлакәтләренең төп сәбәпләре: исерек хәлдә идарә итү, тизлек режимын арттыру, каршы як хәрәкәт полосасына чыгу.

## II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары.

Программаның максаты булып юл-транспорт һәлакәтләреннән үлүчеләр санын (шул исәптән балалар) һәм зыян күрүчеләр булган юл-транспорт

һәлакәтләре санын киметү, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм мал-мөлкәтен саклауны тәэмин итү, аларның район юлларында хәрәкәт итү шартларына законлы хокукларының гарантияләрен арттыру тора.

Программаның бурычлары:

- үлү ихтималы аеручап зур булган юл-транспорт һәлакәтләрен булдырмау;
- юл-транспорт һәлакәтендә җәрәхәтләр авырлыгын киметү;
- юл-транспорт һәлакәтендә зыян күрүчеләргә заманча ярдәм күрсәтү системасын үстерү;
- юл хәрәкәте иминлеген арттыру эшчәнлеге белән идарә итү системасын камилләштерү;
- юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокук белемен һәм җаваплылыгын күтәрү;
- җирле әһәмияттәге юлларда куркыныч участокларны бетерү;
- урамнарда һәм юлларда ЮХК кагыйдәләренә өйрәтү системасын камилләштерү.

## III. Программаның төп чаралары

Программа чаралары комплексы Программаның түбәндәге юнәлешләре буенча капитал кертүләргә һәм башка ихтыяҗларга чыгымнарның статьялары буенча төзелә һәм финанслана.

Хокукый аңны арттыруга һәм юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тотышын кисәтүгә юнәлтелгән чаралар.

Күрсәтелгән юнәлештә эшчәнлек транспорт чараларын йөртүчеләрне, юл хәрәкәтендә башка катнашучыларны әзерләү системаларын камилләштерүне һәм үстерүне, хокуксыз тәртип бозылган очракта хокукый йогынты чараларын эшләүне, шулай ук профилактик эшне камилләштерүне күздә тота. Җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру һәм юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәү буенча махсус пропаганда компанияләрен массакүләм мәгълүмат чараларын кулланып оештыру һәм үткәрү күздә тотыла.

Торак пунктларда транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары.

Күрсәтелгән юнәлештә эшчәнлек транспорт чараларының һәм җәяүлеләрнең хәрәкәт итү шартларын яхшыртуны, транспорт агымнарын җайга салуның заманча ысулларын, юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын кертүне, җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүне, юл-транспорт һәлакәтләре барлыкка килүгә юл шартларының йогынтысын киметүне, урам-юл челтәрен үткәрү сәләтен арттыруны, юл-транспорт һәлакәтләрен концентрацияләү урыннарында инженерлык чараларын уздыруны күздә тота.

Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү системасын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар.

Күрсәтелгән юнәлештә эшчәнлек юл-транспорт һәлакәте урынына аларның нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы хезмәтләрнең килеп җитү вакытын кыскартуны, аларның гамәлләрен тизләтүне һәм җайга салуны, юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыруны күздә тота.

## IV. Программаның ресурс тәэмин ителеше

Программаны ресурслар белән тәэмин итүне планлаштырганда муниципаль һәм региональ дәрәҗәдә финанс-бюджет өлкәсендә реаль вәзгыять, аварияләр торышы, шулай ук республика ярдәме белән аны хәл итүнең реаль мөмкинлеге исәпкә алынды.

Программа чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджетлары, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырылачак.

2020 елгы Программаны финанслауның гомуми күләме 58,0 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы акчалары исәбеннән - 35,0 млн. сум, бюджеттан тыш чыганаклардан  һәм муниципаль бюджеттан - 23,0 млн. сум.

## V. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыруга идарә итүнең рәвешләре һәм ысуллары муниципаль заказчы - Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

Программаны гамәлгә ашыру эшен оештыру өчен Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе төзелде, анда бүлекләр, юл хезмәте, ЮХИДИ, сәламәтлек саклау, мәгариф бүлеге һәм башка кызыксынган структуралар вәкилләре катнашты.

Программалы чаралар шартнамәләр һәм контрактлар нигезендә гамәлгә ашырыла. Чаралар башкару процессы һәм контракт буенча бюджет акчаларын тоту тәртибе Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башыннан алып үтәлгәнчегә кадәр тикшереп торыла.

## VI. Программаның социаль-икътисадый һәм бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны кимү һәм зыян күрүчеләр белән юл-транспорт һәлакәтләре саны азаю Программаның күрсәткечләренә ирешү дәрәҗәсе белән билгеләнә.

Юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокукый аңын күтәрүгә һәм аларның куркыныч тәртибен булдырмауга юнәлдерелгән чаралар, торак пунктларда транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерү, юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү системасын үстерү юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә үлүчеләр санын киметүгә турыдан-туры йогынты ясый.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлеккә идарә итү системасының норматив-хокукый, методик һәм оештыру нигезләрен камилләштерүгә юнәлдерелгән гамәлләр Программаны тулаем гамәлгә ашыру өчен кирәк. Әлеге чаралардан башка Программа үтәлә алмый.

**Юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокукый аңын күтәрүгә һәм хәвефле үз-үзләрен тотышын булдырмауга юнәлдерелгән чаралар ( млн. сум).**

| № | Чаралар исеме | Үтәү срогы | Финанслау күләме | Шул исәптән | | | Үтәлү өчен җаваплылар | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ТР бюджеты акчалары хисабына | Район бюджеты акчалары хисабына | Бюджеттан тыш чыганаклар хисабына | | |
| 1 | “Игътибар – балалар!”, “Игътибар – җәүяле!” ,“Итагатьле машина йөртүче”, “Зебра” һ.б. акцияләр уздыру<br>Юл хәрәкәтендә катнашучыларның дисциплинасын ныгытуга юнәлтелгән профилактик акцияләрне уздыруга мәгълүмати һәм реклама агентлыкларын җәлеп итү, юл хәрәкәте мәсьәләләре буенча материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру | 2020 | 0.03 | - | 0.03 | - | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге, Россия ЭЭМның Кайбыч районы бүлекчә-сенең ЮХИДИ бүлекчәсе | Юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тотышын кисәтү |
| 2 | яктылык кайтаручы җайланмаларны әзерләү һәм тарату | 2020 | 0,04 | - | - | 0,04 | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге, Россия ЭЭМның Кайбыч районы бүлекчә-сенең ЮХИДИ бүлекчәсе | тәүлекнең караңгы вакытында җәяүлене бәрдерү ихтималының кимүе |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Мәгариф учреждениеләрендә балалар юл-транспорт травматизмын профилактикалау мониторингы | 2020 | - | - | - | - | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге, Россия ЭЭМның Кайбыч районы бүлекчә-сенең ЮХИДИ бүлекчәсе | балалар юл-транспорт травматизмын профилактикалау |

**Торак пунктларда транспорт чаралары һәм җәяүлеләрнең хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары (млн. сум)**

| № | Чаралар исеме | Үтәү срогы | Финанслау күләме | Шул исәптән | | | Үтәлү өчен җаваплылар | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ТР бюджеты акчалары хисабына | Район бюджеты акчалары хисабына | Бюджет-тан тыш чыганаклар хисабына | | |
| 1 | Балаларның юл хәрәкәтендә имин катнашуларын тәэмин итүгә, транспорт чараларының һәм җәяүлеләрнең хәрәкәтен оештыру системасын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар | 2020 | 0,8 | | 0,8 | - | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструк-тур үсеш бүлеге, автомобиль юлларын һәм юл- урам челтәрен баланслаучылар, подряд оешмалары | Транспорт чараларының каршы як хәрәкәт полоса-сына һәм тротуарларга чыгу мөмкинлекләрен, күперләрдән, биек өемнәрдән егылу, автомобильнең машина юлына чыгу тизлеген чикләү мөмкинлеген юкка чыгару. |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Кайбыч муниципаль районы торак пунктларының юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү | 2020 | 58,0 | 35,0 | 23,0 | - | «Главтатдортранс» ДКУ, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструк-тур үсеш бүлеге, автомобиль юлларын һәм юл- урам челтәрен баланслаучылар, подряд оешмалары | Муниципаль юлларны үстерү һәм карап тору |

## Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү системасын үстерүгә юнәлдерелгән гамәлләр

| № | Чаралар исеме | Үтәү срогы | Финансла у күләме | Шул исәптән | | | Үтәлү өчен җаваплылар | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ТР бюджет ы акчалар ы хисабын а | Район бюдже-ты акчалары хисабына | Бюджет-тан тыш чыганаклар хисабына | | |
| 1 | Юл-транспорт һәлакәте урынында ашыгыч медицина ярдәмен нәтиҗәле күрсәтү һәм анда зыян күргән затларны дәвалау учреждениеләренә вакытында китерү | 2020 | - | - | - | - | «Үзәк район хастаханәсе» ДАССУ | һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү-дә катнашучы хезмәтләрнең юл-транспорт һәлакәте урынына килү вакытын кыскарту, аларның гамәллә-ренең тизлеген һәм көйлән-гән булуын, юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | арттыруны |
| 2 | Юл-транспорт һәлакәтенә җавап бирү буенча махсус өйрәнүләр - тактико үткәрү | 2020 | - | - | - | - | РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 18 номерлы янгын сүндерү бүлеге | юл-транспорт һәлакәте урынында коткару эшләрен уздыру технологиясен камилләштерү |
| 3 | Гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга һәм һава шартларының начараюына көн саен оператив фараз җиткерүне оештыру кызыксынган оешмаларга кадәр | 2020 | - | - | - | - | РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 18 номерлы янгын сүндерү бүлеге | Юл-транспорт һәлакәтен кисәтү һәм киметү, һава шартларының начараюына бәйле рәвештә |

**«Кайбыч муниципаль районында 2020 елга юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасын республика бюджеты, муниципаль берәмлек бюджеты һәм башка чыганаклар исәбеннән финанслау күләмнәре**
**(млн. сум)**

| Финанслау чыганагы | 2020 ел |
|---|---|
| Татарстан Республикасы бюджеты чаралары - барлыгы | 35,0 |
| Муниципаль берәмлек акчалары - барлыгы | 23.0 |
| Бюджеттан тыш чыганаклар чаралары - барлыгы | 0,04 |
| Программаны барлык чыганаклардан финанслау күләме барлыгы | 58,04 |